**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында
2022 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

**№ 3** **18.12.2021 ел**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципал районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында халык җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Әбсәләм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Әбсәләм торак пунктындагы Совет урамына асфальт салу (сатып алу, алып кайту, түшәү, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Әбсәләм торак пунктындагы Юл буе урамында су линиясе төзү (материаллар, җиһазлар сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- Әбсәләм торак пунктында урам юлларын кардан чистарту, грейдерлаштыру (трактор өчен ягулык, запас частьлар сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

3. Әлеге карарны Әбсәләм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштырырга.

Җыенда рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В.Кубашева